БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» октябрь 2021 ел № 324

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында ихтыяри ярдәм (волонтерлык) мәсьәләләре буенча ведомствоара совет төзү турында

Ихтыяри ярдәмне (волонтерлыкны) үстерү һәм Балтач муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы берләшмәләргә ярдәм итү максатларында, Татарстан Республики Балтач район башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында ихтыяри ярдәм (волонтерлык) мәсьәләләре буенча ведомствоара совет төзергә.
2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында ихтыяри ярдәм (волонтерлык) мәсьәләләре буенча ведомствоара совет турында нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында ихтыяри ярдәм (волонтерлык) мәсьәләләре буенча ведомствоара совет составын расларга (2 нче кушымта).
4. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2021 елның ____________
______ номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында ихтыяри ярдәм (волонтерлык) мәсьәләләре буенча ведомствоара совет турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Балтач муниципаль районында ихтыяри ярдәм (волонтерлык) мәсьәләләре буенча ведомствоара совет (далее Ведомствоара совет) муниципаль хакимият органнарының килешенгән гамәлләрен тәэмин итү һәм аларның ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеге өлкәсендә иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү максатларында оештырылган консультатив орган булып тора.

1.2. Ведомствоара совет үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

## 2. Ведомствоара советның төп бурычлары һәм функцияләре

2.1. Ведомствоара советның төп бурычлары һәм функцияләре булып түбәндәгеләр тора:

- Балтач муниципаль районы муниципаль хакимияте органнарының иҗтимагый оешмалар белән ихтыяри ярдәм (волонтерлык) мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү;
- Балтач муниципаль районында ихтыяри ярдәмнең (волонтерлыкның) өстенлекле юнәлешләренә ярдәм итү һәм ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген тормышка ашыру буенча тәкъдимнәр формалаштыру;
- ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлегенең төп юнәлешләре (мәгариф, сәламәтлек саклау, гражданлык-патриотик тәрбия, мәдәният, социаль ярдәм һәм халыкка социаль хезмәт күрсәтү, физик культура һәм спорт, әйләнә-тирә табигатьне саклау, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, эчке эшләр органнарына ярдәм итү, вакыйгаи, инклюзив, корпоратив ихтыяри ярдәм (волонтерлык), өлкән яшьтәге гражданнарның ихтыяри ярдәме (волонтерлыгы) эшчәнлеге - «көмеш волонтерлык»);
- Балтач муниципаль районында ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген комплекслы анализлау.

## 3. Ведомствоара советның хокуклары

3.1. Үзенә йөкләнгән функцияләрне үтәү өчен ведомствоара совет түбәндәгеләргә хокуклы:

- Балтач муниципаль районында ихтыяри ярдәм (волонтерлык) үсешенең өстенлекле юнәлешләре буенча тәкъдимнәр кертергә;

- үз утырышларында ведомствоара совет эшчәнлегенә караган мәсьәләләрне карарга һәм алар буенча карарлар кабул итәргә.

## 4. Ведомствоара советның составы һәм аның эшчәнлеген оештыру

4.1. Ведомствоара совет Совет рәисе, Совет рәисе урынбасары һәм Советның башка әгъзалары составында формалаша.

4.2. Ведомствоара совет составы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе карары белән раслана.

4.3. Ведомствоара совет рәисе аның эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, Ведомствоара совет утырышларын үткәрә, Ведомствоара советның эш планын раслый, Ведомствоара совет эшчәнлеге кысаларында Ведомствоара совет әгъзалары арасында вазыйфаларны, аңа йөкләнгән бурычларны һәм функцияләрне билгели, Ведомствоара совет әгъзаларына тиешле йөкләмәләр бирә, Ведомствоара советның беркетмәләренә һәм башка документларына имза куя.

4.4. Ведомствоара совет рәисе булмаганда, аның вәкаләтләрен Ведомствоара совет рәисе кушуы буенча Ведомствоара совет рәисе урынбасары гамәлгә ашыра.

4.5. Ведомствоара совет утырышлары кирәк булган саен, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Әгәр утырышта аның әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, Ведомствоара совет утырышы тулы хокуклы дип санала. Ведомствоара совет утырышларына материаллар Ведомствоара совет әгъзаларына Ведомствоара совет секретаре тарафыннан Ведомствоара совет утырышы уздырыласы көнгә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча җибәрелергә тиеш.

4.6. Ведомствоара совет әгъзасы Ведомствоара совет утырышларында шәхсән катнашырга бурычлы. Утырышта катнашу мөмкин булмаган очракта, Ведомствоара совет әгъзасы бу хакта Ведомствоара совет рәисенә хәбәр итәргә тиеш.

4.7. Ведомствоара совет утырышларында карала торган мәсьәләләр утырышта катнашучы затларның гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә торган Ведомствоара совет карары белән рәсмиләштерелә, Ведомствоара совет рәисе тарафыннан имзалана торган утырыш беркетмәләре белән рәсмиләштерелә. Тавышлар саны тигез булганда, Ведомствоара совет рәисе яисә Ведомствоара совет утырышында рәислек

итүче Ведомствоара совет рәисе урынбасарының тавышы хәлиткеч булып тора.

4.8. Ведомствоара совет утырышы нәтиҗәләре буенча беркетмәләр утырыш уздырылган көннән 10 эш көне эчендә рәсмиләштерелә һәм Ведомствоара совет рәисе имза куйганнан соң өч көн эчендә йөкләмәләрне үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затларга җибәрелә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2021 елның ___________
______ номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында ихтыяри ярдәм (волонтерлык) мәсьәләләре буенча ведомствоара совет
СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Гайнетдинов Илһам Фидәел улы | Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, совет рәисе |
| Заһидуллин Рөстәм Рафис улы | Балтач район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы, совет рәисе урынбасары |

**Совет әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Петров Ильназ Ильич | Балтач район башкарма комитеты мәдәният бүлеге башлыгы |
| Шагаева Алия Юныс кызы | «Балтач район башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы |
| Дәүлиев Газинур Дәүли улы | «Балтач РҮХ» ДАССУ баш табибы |
| Гатиятуллина Алсу Фәриз кызы | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге башлыгы |
| Низамиев Наил Ильвер улы | Балтач муниципаль районының ихтыяри ярдәм үзәге җитәкчесе |